*Муниципаль тур*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕНЕҢ
**ҖАВАПЛАРЫ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**8 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 62**

## I. Тестлардан дөрес җавапны билгеләгез.

1. Ирен ассимиляциясе күзәтелгән сүз кергән мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) Кая барсаң да, бер кояш.
   **ә) Кояш барда, йолдыз күренми.**
   б) Кояш та тапсыз булмый.
   в) Кызарып чыккан кояшны болыт каплый.
2. Нокталар урынына **ә** хәрефе языла торган сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) мәшәк..ть
   ә) мәгълүм..ть
   **б) һәмм..**
   в) гыйб..рәт
3. Фразеологизмның мәгънәсен билгеләгез. **(2 балл)**
   ***бака туе ясау***
   а) бик күп кеше җыелган урын
   ә) кунаклар аз булган туй
   **б) бер-берсен тыңламыйча, кычкырып сөйләшү**
   в) сугышу, кычкырышу
4. Ономастикага туры килә торган аңлатманы билгеләгез. **(2 балл)**
   а) сүзләрне өйрәнә
   **ә) ялгызлык исемнәрен өйрәнә**
   б) сүзләрнең килеп чыгышын өйрәнә
   в) сүзләрнең тарихын өйрәнә
5. Мәгънәдәш сүзләр ярдәмендә ясалган парлы сүзне билгеләгез. **(2 балл)**
   а) берән-сәрән
   ә) аз-маз
   б) эреле-ваклы
   **в) иелә-бөгелә**
6. Кимлек дәрәҗәсендә кулланылмый торган сыйфатны билгеләгез. **(2 балл)**
   а) салкын
   ә) җылы
   б) әче
   **в) табигый**

7. Шарт фигыль кулланылган мәкальне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Ашыккан су диңгезгә җитмәс.

ә) Тау булгач, чокыры булыр.

**б) Уйнап сөйләсәң дә, уйлап сөйлә.**

в) Абынмас җирдә абынма, абруең төшәр.

8. Ымлыкны билгеләгез. **(2 балл)**

**а) хуш**

ә) әлбәттә

б) ягъни

в) түгел

9. Җөмләдәге калын хәрефләр белән бирелгән сүзнең нинди җөмлә кисәге икәнлеген билгеләгез. **(2 балл)**

*Ишегалдыннан аккан* ***суның*** *кадере юк*. (Мәкаль)

а) ия

ә) хәбәр

**б) аергыч**

в) тәмамлык

10. Инкяр җөмләне билгеләгез. **(2 балл)**

а) Күл булса, бака борынын тыгар. (Мәкаль)

**ә) Яхшы суны ерак түкмиләр. (Мәкаль)**

б) Су чокыр җиргә җыелыр. (Мәкаль)

в) Болганган су тирән күренер. (Мәкаль)

## II. Теоретик бирем.

Сызыклар өстенә тиешле сүзләрне языгыз. **(6 балл)**

Яңгырау тартыкларның җидесе сонор тартыклар дип атала. Сүздәге авазларны ишетелгәнчә язу – фонетик принцип. Билгеле бер төбәктә яшәүчеләр генә куллана торган сүзләр – диалекталь сүзләр. Форма ясагыч кушымчалар нигез эченә керми. Сан ачыклаган исем саналмыш дип атала. Тезүле бәйләнешне белдерә торган чаралар – интонация һәм тезүче теркәгечләр.

## III. Башыгызны эшләтегез.

Парлы сүзләрнең беренче компонентларын уйлап языгыз. **(4 балл)**

моң-зар рәхим-шәфкать

әрәм-шәрәм бәла-каза

## IV. Гамәли-иҗади бирем.

1. Җөмләләрне татар теленә тәрҗемә итеп языгыз. **(6 балл)**

Всё небо в тучах. Часто идут дожди. Дует злой ветер. Люди надели на себя тёплые вещи. С огородов и полей убрали последние овощи.

2. Шигырьне укыгыз һәм биремнәрне эшләгез.

СӘГАТЬ

Тау артыннан кояш чыгып, таң аттыра,

Күккә менеп, безнең эшне карап тора.
Менә сәгать, барчабызны эшкә чакырып,
«Тик-тик» үткән секундларны санап тора.
Сәгать әйтә: – Әйдә, иптәш, әйдә,
Заман белән бергә атла, бергә өйрән.
Минутларның, секундларның кадерен бел, – ди, –
Укуың калса, үкенерсең вакыт үткәч.

*(Гамил Афзал)*

2.1. Сингармонизм законының рәт гармониясенә буйсынмаган сүзләрне күчереп языгыз. **(2 балл) (секундларны, минутларның, секундларның)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.2. Саңгыраулыкта охшашлану күзәтелгән сүзләрне күчереп языгыз. **(3 балл) (аттыра, күккә, эшкә, үткән, иптәш, үткәч)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.3. Басымы соңгы иҗеккә төшмәгән сүзләрнең санын языгыз. **(2 балл) (8)**

2.4. Гарәп-фарсы алынмаларын күчереп языгыз. **(3 балл) (сәгать, заман, вакыт)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.5. Затланышсыз фигыльләрне күчереп языгыз. **(3 балл) (чыгып, менеп, карап, чакырып, үткән, санап, үткәч)** (артык сүз язылса, балл киметелә!)

2.6. Эндәш сүзне күчереп языгыз. **(1 балл) (иптәш)**

3. **«Буш вакытымны файдалы үткәрәм»** дигән темага 8-10 җөмләдән торган инша языгыз. **(12 балл)**